ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 119-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин белән берлектә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 119-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 29 октябре
№ 431-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.Г. Хәбибуллин белән берлектә
Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе
тарафыннан кертелә

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 44 (I өлеш), № 79 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяга түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәргә:

«16. Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе халкы турында белешмәләрне үз эченә алган бердәм федераль мәгълүмат регистрындагы белешмәләр «Россия Федерациясе халкы турында белешмәләрне үз эченә алган бердәм федераль мәгълүмат регистры турында» 2020 елның 8 июнендәге 168-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә комиссияләргә сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләрне алар тарафыннан гамәлгә ашыру максатларында файдалану өчен бирелә.»;

2) 17 статьяның 1 пунктында:

а) түбәндәге эчтәлекле «а$^1$» пунктчасын өстәргә:

«а$^1$) референдумны әзерләү һәм уздыру, автоматлаштыру чараларын кертү, эксплуатацияләү һәм үстерү, референдум оештыручыларын укыту, тиешле басма продукцияне чыгару белән бәйле чараларны башкаруны тәэмин итә;»;

б) түбәндәге эчтәлекле «з$^1$» пунктчасын өстәргә:

«з$^1$) әлеге Законның 17 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән махсус участок комиссияләренең вәкаләтләрен тәэмин итүгә федераль бюджеттан бүлеп

бирелгән акчаларны тотуны гамәлгә ашыра;»;

3) 18 статьяга түбәндәге эчтәлекле «а[1]» пунктчасын өстәргә:

«а[1]) референдумны әзерләү һәм уздыру, автоматлаштыру чараларын кертү, эксплуатацияләү һәм үстерү, референдум оештыручыларны укыту белән бәйле чараларны башкаруны тиешле территориядә тәэмин итә;»;

4) түбәндәге эчтәлекле 23[1] статья өстәргә:

«23[1] статья. **Комиссияләр тарафыннан мөрәҗәгатьләрне карау тәртибе**

1. Гражданнарның, аларның берләшмәләренең, башка оешмаларның һәм аларның вазыйфаи затларының мөрәҗәгатьләре, шул исәптән шикаятьләр, комиссияләр тарафыннан Федераль законда билгеләнгән тәртиптә законда каралган компетенциягә ярашлы рәвештә карала.

2. Мөрәҗәгать комиссиягә Федераль закон нигезендә язма рәвештә, ә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә шулай ук, мөрәҗәгать итүче «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен файдалана торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы яисә мөрәҗәгать итүчеләрнең идентификациясен һәм (яисә) аутентификациясен тәэмин итүче дәүләт органнарының яисә җирле үзидарә органнарының башка мәгълүмат системасы ярдәмендә идентификация һәм аутентификация узганнан соң, комиссияләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтыннан файдаланып, электрон документ рәвешендә бирелергә мөмкин. Мөрәҗәгать электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин башка комиссияләр, шулай ук электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгатьләрне комиссияләргә юллау ысуллары һәм комиссияләрнең аларны эшкәртү тәртибе Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

3. Мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) (физик затлар булып тормаган мөрәҗәгать итүчеләр өчен – исеме) күрсәтелгән булырга тиеш. Язма рәвештәге мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгатькә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелергә, мөрәҗәгать итүченең яисә аның исеменнән эш йөртергә вәкаләтле затның шәхси имзасы һәм мөрәҗәгатьне имзалау датасы булырга тиеш. Электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгатькә җавап юлланырга тиешле электрон почта адресы күрсәтелгән булырга тиеш.

4. Комиссиягә әлеге комиссия тавыш бирүгә йомгаклар чыгарганчы һәм референдум нәтиҗәләре билгеләнгәнче кергән һәм хәл ителеше әлеге комиссия компетенциясенә кермәгән мәсьәләләрне үз эченә алган референдум кампаниясе белән бәйле мөрәҗәгать комиссиягә, компетенциясенә аны карау кергән башка органга яки вазыйфаи затка керү көненнән соң биш эш көне эчендә, ә бүтән чорда кергән йә референдум кампаниясенә бәйле булмаган мөрәҗәгать – керү көненнән соң җиде көн эчендә юллана. Мөрәҗәгатьнең комиссиягә, бүтән органга яисә вазыйфа затка юллануы турында берүк вакытта мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

5. Гражданнарның референдумда катнашу хокукын гамәлгә ашыруга һәм яклауга бәйле булмаган, комиссиягә референдум кампаниясе чорында кергән мөрәҗәгать, шулай ук референдум кампаниясе чорыннан башка вакытта яисә әлеге комиссия тавыш бирүгә йомгаклар чыгаргач, референдум нәтиҗәләре билгеләнгәч кергән мөрәҗәгать керү көненнән соң 30 көн эчендә карала. Аерым очракларда комиссиянең вәкаләтле вазыйфаи заты мөрәҗәгатьне карау срогын, мөрәҗәгать итүчегә аны карау срогын озайту турында хәбәр итеп, иң күбе 30 көнгә озайтырга хокуклы.

6. Әгәр мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгать итүченең фамилиясе (физик зат булып тормаган мөрәҗәгать итүче өчен – исеме) яисә мөрәҗәгатькә җавап җибәрелергә тиешле адресы күрсәтелмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми. Мөрәҗәгать тексты укырлык булмаса яисә мөрәҗәгатьнең асылын ачыкларга мөмкинлек бирмәсә, мондый мөрәҗәгатькә җавап бирелми, бу хакта мөрәҗәгать кергән көннән соң җиде көн эчендә, әгәр мөрәҗәгать итүченең фамилиясе (физик зат булып тормаган мөрәҗәгать итүче өчен – исеме) һәм мөрәҗәгатькә җавап җибәрелергә тиешле адрес укырлык булса, мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

7. Комиссиягә мөрәҗәгать итү хокукыннан әдәпсез йә кимсетүле гыйбарәләр, вазыйфаи затның яисә башка затларның тормышына, сәламәтлегенә, мөлкәтенә янаулар булган мөрәҗәгать җибәрү юлы белән явыз ниятә файдалану рөхсәт ителми. Мондый мөрәҗәгать кергән очракта комиссия мондый мөрәҗәгатьне җавапсыз калдырырга, бу хакта мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итеп, хокуклы. Мөрәҗәгатьтә элек җибәрелгән мөрәҗәгатьләргә бәйле рәвештә асылы буенча язмача җаваплар мөрәҗәгать итүчегә берничә тапкыр бирелгән мәсьәлә бәян ителсә һәм шул ук вакытта яңа дәлилләр яисә шартлар китерелмәсә, әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итүче белән хат алышу, мөрәҗәгать итүчегә бу хакта хәбәр ителеп, туктатылырга мөмкин.

8. Дәүләт органнары булып торучы комиссияләр гражданнарны, аларның берләшмәләре һәм бүтән оешмалар вәкилләрен шәхси кабул итүне үткәрә. Телдән мөрәҗәгатькә турыдан-туры шәхси кабул итү барышында телдән җавап бирелә. Шәхси кабул итү барышында шулай ук язма рәвештә мөрәҗәгать бирелергә мөмкин. Әгәр телдән мөрәҗәгатьтә бәян ителгән шартлар тикшерүне таләп итсә, мондый мөрәҗәгатькә Федераль законда тиешле мөрәҗәгатьне карау өчен билгеләнгән срокта язмача җавап бирелә.

9. Әлеге статья нигезләмәләренең гамәлдә булуы карауның бүтән тәртибе Федераль законда билгеләнгән комиссиягә мөрәҗәгатьләргә кагылмый.»;

5) 43 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^{1-1}$ пункт өстәргә:

«$1^{1-1}$. Федераль закон нигезендә әлеге Законның 17 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән махсус участок комиссияләренең вәкаләтләрен тәэмин итү белән бәйле чыгымнар федераль бюджет акчалары исәбеннән Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан башкарыла.»;

б) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Референдум әзерләү һәм уздыру, автоматлаштыру чараларын

эксплуатацияләү һәм үстерү, референдум оештыручыларны укыту, комиссияләр эшчәнлеген тәэмин итү өчен счетлар ачу һәм алып бару, Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә, башка комиссияләргә бүлеп бирелгән акчаларны исәпкә алу, хисаплылык һәм аларны күчерү тәртибе, Татарстан Республикасы Милли банкы белән килештереп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Акчалар Россия Федерациясе Үзәк банкының исәп-хисап касса хезмәт күрсәтүләрен гамәлгә ашыручы учреждениеләрендә, ә комиссиянең вәкаләтләре тарала торган территориядә алар булмаган очракта – «Россия Саклык банкы» гавами акционер җәмгыяте филиалларында комиссияләр (территория комиссияләреннән тыш) өчен ачыла торган счетларга күчерелә. Территория комиссияләренә акчалар күрсәтелгән комиссияләргә «Россия Саклык банкы» гавами акционер җәмгыяте филиалларында ачыла торган счетларга күчерелә, аның белән банк счеты шартнамәсендә мондый акчаларның кулланылышын тикшереп тору максатларында күрсәтелгән комиссияләрнең «Россия Саклык банкы» гавами акционер җәмгыяте тарафыннан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе счеты буенча операцияләр турында белешмәләр бирүгә ризалыгы хакында шарт карала.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пункт өстәргә:

«$6^1$. Федераль закон нигезендә «Россия Саклык банкы» гавами акционер җәмгыяте филиаллары Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә, күрсәтелгән кредит оешмалары һәм Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе яисә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе арасындагы килешүләргә нигезләнеп, түбәнрәк сайлау комиссияләренә ачылган счетлар буенча операцияләр турында белешмәләр тапшыра.»;

6) 44 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $5^2$ пункт өстәргә:

«$5^2$. Гражданның референдум фондына ихтыярый иганәсе шәхсән граждан тарафыннан, паспорт яисә граждан паспортын алмаштыручы документны күрсәтеп, элемтә бүлегенә, кредит оешмасына үз акчаларыннан кертелә. Иганә керткәндә граждан түләү документында үзе турында түбәндәге белешмәләрне күрсәтә: фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, яшәү урынының адресын, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын, гражданлыгы турында мәгълүматны.»;

б) 9 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Референдум фондының махсус счеты шәхсән булмаганда да (дистанцион) ачылырга мөмкин.»;

в) 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Әлеге статьяның 9 пунктында күрсәтелгән счетны ачу, алып бару һәм ябу тәртибе, Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Күрсәтелгән тәртиптә референдум фондының махсус счетын шәхсән булмаганда (дистанцион) ачу, алып бару һәм ябуның үзенчәлекләре билгеләнә. Референдум фонды акчалары керү һәм аларны тоту турында, шул исәптән һәр операция буенча, исәпкә алу һәм хисаплылык тәртибе һәм рәвешләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе

тарафыннан билгеләнә.»;

7) 45 статьяның 10 пунктындагы икенче җөмләне төшереп калдырырга;

8) 50 статьяда:

а) 9 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Әгәр референдумда катнашучы бозылганы урынына яңа бюллетень бирүне үтенеп кабат мөрәҗәгать итсә, мондый бюллетеньне бирү турында карар участок комиссиясе тарафыннан кабул ителә.»;

б) 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Референдум үткәргәндә электрон тавыш бирү үткәрелергә мөмкин. Электрон тавыш бирү үткәргәндә кәгазьдә әзерләнгән бюллетеньнәрне файдалану мөмкинлеге тәэмин ителгән булырга тиеш. Федераль закон нигезендә электрон тавыш бирү үткәрү турындагы карар Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан яисә аның кушуы буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан кабул ителә. Электрон тавыш бирү, референдумда катнашучыларның тавышларын санау тәртибе һәм референдум участогында тавыш бирү йомгакларын билгеләү һәм, электрон тавыш бирү йомгакларын исәпкә алып, референдум нәтиҗәләрен билгеләү Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе яисә аның кушуы буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

9) $50^2$ статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $10^1$ пункт өстәргә:

«$10^1$. Татарстан Республикасы территориясендә берьюлы дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү һәм электрон тавыш бирү үткәрелгән очракта дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү тәртибендә электрон тавыш бирү нәтиҗәләре дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү нәтиҗәләрендә исәпкә алына дип каралырга мөмкин.»;

б) 13 пунктта дүртенче җөмләне төшереп калдырырга;

10) 53 статьяның 33 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«33. Федераль закон нигезендә тавышларны техник санау чараларыннан, электрон тавыш бирү комплексларыннан, референдум турында мәгълүмат тапшыруның техник системасыннан файдалану тәртибе, күрсәтелгән мәгълүматны тапшыру, эшкәртү һәм аннан файдалану тәртибе һәм вакытлары, шул исәптән тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмәләрдәге мәгълүматларны техник элемтә каналлары буенча тапшырылганнарны да, федераль закон белән, ә федераль закон белән җайга салынмаган өлешендә — Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан яисә аның кушуы буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.».

**2 статья**

«Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы

Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (II өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (II өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 44 (I өлеш), № 79 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 19 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $15^1$ пункт өстәргә:

«$15^1$. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе халкы турында белешмәләрне үз эченә алган бердәм федераль мәгълүмат регистрындагы белешмәләр «Россия Федерациясе халкы турында белешмәләрне үз эченә алган бердәм федераль мәгълүмат регистры турында» 2020 елның 8 июнендәге 168-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә комиссияләргә сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләрне алар тарафыннан гамәлгә ашыру максатларында файдалану өчен бирелә.»;

б) 18 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2) түбәндәге эчтәлекле $25^1$ статья өстәргә:

«$25^1$ статья. **Комиссияләр тарафыннан мөрәҗәгатьләрне карау тәртибе**

1. Гражданнарның, аларның берләшмәләренең, башка оешмаларның һәм аларның вазыйфаи затларының мөрәҗәгатьләре, шул исәптән шикаятьләр, комиссияләр тарафыннан «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда билгеләнгән тәртиптә законда каралган компетенциягә ярашлы рәвештә карала.

2. Мөрәҗәгать комиссиягә «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә язма рәвештә, ә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә шулай ук, мөрәҗәгать итүче «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен файдалана торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы яисә мөрәҗәгать итүчеләрнең идентификациясен һәм (яисә) аутентификациясен тәэмин итүче дәүләт органнарының яисә җирле үзидарә органнарының башка мәгълүмат системасы ярдәмендә идентификация һәм аутентификация узганнан соң, комиссияләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтыннан файдаланып, электрон документ рәвешендә бирелергә мөмкин. Мөрәҗәгать электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин башка комиссияләр, шулай ук электрон документ рәвешендәге

мөрәҗәгатьләрне комиссияләргә юллау ысуллары һәм комиссияләрнең аларны эшкәртү тәртибе Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

3. Мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) (физик затлар булып тормаган мөрәҗәгать итүчеләр өчен – исеме) күрсәтелгән булырга тиеш. Язма рәвештәге мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгатькә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелергә, мөрәҗәгать итүченең яисә аның исеменнән эш йөртергә вәкаләтле затның шәхси имзасы һәм мөрәҗәгатьне имзалау датасы булырга тиеш. Электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгатькә җавап юлланырга тиешле электрон почта адресы күрсәтелгән булырга тиеш.

4. Комиссиягә әлеге комиссия тавыш бирүгә йомгаклар чыгарганчы һәм референдум нәтиҗәләре билгеләнгәнче кергән һәм хәл ителеше әлеге комиссия компетенциясенә кермәгән мәсьәләләрне үз эченә алган референдум кампаниясе белән бәйле мөрәҗәгать комиссиягә, компетенциясенә аны карау кергән башка органга яки вазыйфаи затка керү көненнән соң биш эш көне эчендә, ә бүтән чорда кергән йә референдум кампаниясенә бәйле булмаган мөрәҗәгать – керү көненнән соң җиде көн эчендә юллана. Мөрәҗәгатьнең комиссиягә, бүтән органга яисә вазыйфа затка юллануы турында беркүк вакытта мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

5. Гражданнарның референдумда катнашу хокукын гамәлгә ашыруга һәм яклауга бәйле булмаган, комиссиягә референдум кампаниясе чорында кергән мөрәҗәгать, шулай ук референдум кампаниясе чорыннан башка вакытта яисә әлеге комиссия тавыш бирүгә йомгаклар чыгаргач, референдум нәтиҗәләре билгеләнгәч кергән мөрәҗәгать керү көненнән соң 30 көн эчендә карала. Аерым очракларда комиссиянең вәкаләтле вазыйфаи заты мөрәҗәгатьне карау срогын, мөрәҗәгать итүчегә аны карау срогын озайту турында хәбәр итеп, иң күбе 30 көнгә озайтырга хокуклы.

6. Әгәр мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгать итүченең фамилиясе (физик зат булып тормаган мөрәҗәгать итүче өчен – исеме) яисә мөрәҗәгатькә җавап җибәрелергә тиешле адресы күрсәтелмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми. Мөрәҗәгать тексты укырлык булмаса яисә мөрәҗәгатьнең асылын ачыкларга мөмкинлек бирмәсә, мондый мөрәҗәгатькә җавап бирелми, бу хакта мөрәҗәгать кергән көннән соң җиде көн эчендә, әгәр мөрәҗәгать итүченең фамилиясе (физик зат булып тормаган мөрәҗәгать итүче өчен – исеме) һәм мөрәҗәгатькә җавап җибәрелергә тиешле адрес укырлык булса, мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

7. Комиссиягә мөрәҗәгать итү хокукыннан әдәпсез йә кимсетүле гыйбарәләр, вазыйфаи затның яисә башка затларның тормышына, сәламәтлегенә, мөлкәтенә янаулар булган мөрәҗәгать җибәрү юлы белән явыз нияттә файдалану рөхсәт ителми. Мондый мөрәҗәгать кергән очракта комиссия мондый мөрәҗәгатьне җавапсыз калдырырга, бу хакта мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итеп, хокуклы. Мөрәҗәгатьтә элек җибәрелгән мөрәҗәгатьләргә бәйле рәвештә асылы буенча язмача җаваплар мөрәҗәгать итүчегә берничә тапкыр бирелгән мәсьәлә бәян ителсә һәм шул ук вакытта яңа дәлилләр яисә шартлар китерелмәсә, әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итүче белән хат алышу, мөрәҗәгать итүчегә бу хакта хәбәр ителеп, туктатылырга мөмкин.

8. Дәүләт органнары булып торучы комиссияләр гражданнарны, аларның

берләшмәләре һәм бүтән оешмалар вәкилләрен шәхси кабул итүне үткәрә. Телдән мөрәҗәгатькә турыдан-туры шәхси кабул итү барышында телдән җавап бирелә. Шәхси кабул итү барышында шулай ук язма рәвештә мөрәҗәгать бирелергә мөмкин. Әгәр телдән мөрәҗәгатьтә бәян ителгән шартлар тикшерүне таләп итсә, мондый мөрәҗәгатькә Федераль законда тиешле мөрәҗәгатьне карау өчен билгеләнгән срокта язмача җавап бирелә.

9. Әлеге статья нигезләмәләренең гамәлдә булуы карауның бүтән тәртибе «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда билгеләнгән комиссиягә мөрәҗәгатьләргә кагылмый.»;

3) 45 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Референдум әзерләү һәм уздыру, автоматлаштыру чараларын эксплуатацияләү һәм үстерү, референдумнар оештыручыларын укыту, комиссияләр эшчәнлеген тәэмин итү өчен счетлар ачу һәм алып бару, җирле бюджеттан комиссияләргә бүлеп бирелгән акчаларны исәпкә алу, хисаплылык һәм аларны күчерү тәртибе, Татарстан Республикасы Милли банкының территориаль учреждениесе белән килештереп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Территория комиссияләренә акчалар күрсәтелгән комиссияләргә «Россия Саклык банкы» гавами акционер җәмгыяте филиалларында ачыла торган счетларга күчерелә.»;

4) 46 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $5^2$ пункт өстәргә:

«$5^2$. Гражданның референдум фондына ихтыярый иганәсе шәхсән граждан тарафыннан, паспорт яисә граждан паспортын алмаштыручы документны күрсәтеп, элемтә бүлегенә, кредит оешмасына үз акчаларыннан кертелә. Иганә керткәндә граждан түләү документында үзе турында түбәндәге белешмәләрне күрсәтә: фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, яшәү урынының адресын, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын, гражданлыгы турында мәгълүматны.»;

б) 9 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Референдум фондының махсус счеты шәхсән булмаганда да (дистанцион) ачылырга мөмкин.»;

в) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Әлеге статьяның 9 пунктында күрсәтелгән счетны ачу, алып бару һәм ябу тәртибе, Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Күрсәтелгән тәртиптә референдум фондының махсус счетын шәхсән булмаганда (дистанцион) ачу, алып бару һәм ябуның үзенчәлекләре билгеләнә. Референдум фонды акчалары керү һәм аларны тоту турында, шул исәптән һәр операция буенча, исәпкә алу һәм хисаплылык тәртибе һәм рәвешләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

5) 47 статьяның 10 пунктындагы икенче җөмләне төшереп калдырырга;

б) 52 статьяда:

а) 9 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Әгәр референдумда катнашучы бозылганы урынына яңа бюллетень бирүне үтенеп кабат мөрәҗәгать итсә, мондый бюллетеньне бирү турында карар участок комиссиясе тарафыннан кабул ителә.»;

б) 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Референдум үткәргәндә электрон тавыш бирү үткәрелергә мөмкин. Электрон тавыш бирү үткәргәндә кәгазьдә әзерләнгән бюллетеньнәрне файдалану мөмкинлеге тәэмин ителгән булырга тиеш. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә электрон тавыш бирү үткәрү турындагы карар Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан яисә аның кушуы буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан кабул ителә. Электрон тавыш бирү, референдумда катнашучыларның тавышларын санау тәртибе һәм референдум участогында тавыш бирү йомгакларын билгеләү һәм, электрон тавыш бирү йомгакларын исәпкә алып, референдум нәтиҗәләрен билгеләү Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе яисә аның кушуы буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

в) 15 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

7) $52^1$ статьяның 17 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

8) $52^2$ статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $10^1$ пункт өстәргә:

«$10^1$. Татарстан Республикасы территориясендә берьюлы дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү һәм электрон тавыш бирү үткәрелгән очракта дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү тәртибендә электрон тавыш бирү нәтиҗәләре дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү нәтиҗәләрендә исәпкә алына дип каралырга мөмкин.»;

б) 13 пунктта дүртенче җөмләне төшереп калдырырга;

9) 53 статьяның 19 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

10) 55 статьяга түбәндәге эчтәлекле $30^3$ пункт өстәргә:

«$30^3$. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә тавышларны техник санау чараларыннан, электрон тавыш бирү комплексларыннан, референдум турында мәгълүмат тапшыруның техник системасыннан файдалану тәртибе, күрсәтелгән мәгълүматны тапшыру, эшкәртү һәм аннан файдалану тәртибе һәм вакытлары, шул исәптән тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмәләрдәге мәгълүматларны техник элемтә каналлары буенча тапшырылганнарны да, федераль закон белән, ә федераль закон белән җайга салынмаган өлешендә — Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан

яисә аның кушуы буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.».

**3 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 44 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2025, № 33 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяга түбәндәге эчтәлекле 18 өлеш өстәргә:

«18. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе халкы турында белешмәләрне үз эченә алган бердәм федераль мәгълүмат регистрындагы белешмәләр «Россия Федерациясе халкы турында белешмәләрне үз эченә алган бердәм федераль мәгълүмат регистры турында» 2020 елның 8 июнендәге 168-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә комиссияләргә сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләрне алар тарафыннан гамәлгә ашыру максатларында файдалану өчен бирелә.»;

2) 15 статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Территория комиссиясе вәкаләтләре Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше административ-территориаль берәмлекне бетерүгә китергән итеп үзгәртелгән йә тиешле муниципаль берәмлек үзгәртеп корылган очракта, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе белән килештереп кабул ителгән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән туктатылырга мөмкин.»;

3) түбәндәге эчтәлекле $17^{1}$ статья өстәргә:

«$17^{1}$ статья. **Комиссияләр тарафыннан мөрәҗәгатьләрне карау тәртибе**

1. Гражданнарның, аларның берләшмәләренең, башка оешмаларның һәм аларның вазыйфаи затларының мөрәҗәгатьләре, шул исәптән шикаятьләр, комиссияләр тарафыннан «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда билгеләнгән тәртиптә законда каралган компетенциягә ярашлы рәвештә карала.

2. Мөрәҗәгать комиссиягә «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында»

Федераль закон нигезендә язма рәвештә, ә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә шулай ук, мөрәҗәгать итүче «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен файдалана торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы яисә мөрәҗәгать итүчеләрнең идентификациясен һәм (яисә) аутентификациясен тәэмин итүче дәүләт органнарының яисә җирле үзидарә органнарының башка мәгълүмат системасы ярдәмендә идентификация һәм аутентификация узганнан соң, комиссияләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтыннан файдаланып, электрон документ рәвешендә бирелергә мөмкин. Мөрәҗәгать электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин башка комиссияләр, шулай ук электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгатьләрне комиссияләргә юллау ысуллары һәм комиссияләрнең аларны эшкәртү тәртибе Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

3. Мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) (физик затлар булып тормаган мөрәҗәгать итүчеләр өчен – исеме) күрсәтелгән булырга тиеш. Язма рәвештәге мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгатькә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелергә, мөрәҗәгать итүченең яисә аның исеменнән эш йөртергә вәкаләтле затның шәхси имзасы һәм мөрәҗәгатьне имзалау датасы булырга тиеш. Электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгатькә җавап юлланырга тиешле электрон почта адресы күрсәтелгән булырга тиеш.

4. Комиссиягә әлеге комиссия тавыш бирүгә йомгаклар чыгарганчы һәм референдум нәтиҗәләре билгеләнгәнче кергән һәм хәл ителеше әлеге комиссия компетенциясенә кермәгән мәсьәләләрне үз эченә алган референдум кампаниясе белән бәйле мөрәҗәгать комиссиягә, компетенциясенә аны карау кергән башка органга яки вазыйфаи затка керү көненнән соң биш эш көне эчендә, ә бүтән чорда кергән йә референдум кампаниясенә бәйле булмаган мөрәҗәгать – керү көненнән соң җиде көн эчендә юллана. Мөрәҗәгатьнең комиссиягә, бүтән органга яисә вазыйфа затка юллануы турында берүк вакытта мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

5. Гражданнарның референдумда катнашу хокукын гамәлгә ашыруга һәм яклауга бәйле булмаган, комиссиягә референдум кампаниясе чорында кергән мөрәҗәгать, шулай ук референдум кампаниясе чорыннан башка вакытта яисә әлеге комиссия тавыш бирүгә йомгаклар чыгаргач, референдум нәтиҗәләре билгеләнгәч кергән мөрәҗәгать керү көненнән соң 30 көн эчендә карала. Аерым очракларда комиссиянең вәкаләтле вазыйфаи заты мөрәҗәгатьне карау срогын, мөрәҗәгать итүчегә аны карау срогын озайту турында хәбәр итеп, иң күбе 30 көнгә озайтырга хокуклы.

6. Әгәр мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгать итүченең фамилиясе (физик зат булып тормаган мөрәҗәгать итүче өчен – исеме) яисә мөрәҗәгатькә җавап җибәрелергә тиешле адресы күрсәтелмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми. Мөрәҗәгать тексты укырлык булмаса яисә мөрәҗәгатьнең асылын ачыкларга мөмкинлек бирмәсә, мондый мөрәҗәгатькә җавап бирелми, бу хакта мөрәҗәгать кергән көннән соң җиде көн эчендә, әгәр мөрәҗәгать итүченең фамилиясе (физик зат булып

тормаган мөрәҗәгать итүче өчен – исеме) һәм мөрәҗәгатькә җавап җибәрелергә тиешле адрес укырлык булса, мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

7. Комиссиягә мөрәҗәгать итү хокукыннан әдәпсез йә кимсетүле гыйбарәләр, вазыйфаи затның яисә башка затларның тормышына, сәламәтлегенә, мөлкәтенә янаулар булган мөрәҗәгать җибәрү юлы белән явыз нияттә файдалану рөхсәт ителми. Мондый мөрәҗәгать кергән очракта комиссия мондый мөрәҗәгатьне җавапсыз калдырырга, бу хакта мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итеп, хокуклы. Мөрәҗәгатьтә элек җибәрелгән мөрәҗәгатьләргә бәйле рәвештә асылы буенча язмача җаваплар мөрәҗәгать итүчегә берничә тапкыр бирелгән мәсьәлә бәян ителсә һәм шул ук вакытта яңа дәлилләр яисә шартлар китерелмәсә, әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итүче белән хат алышу, мөрәҗәгать итүчегә бу хакта хәбәр ителеп, туктатылырга мөмкин.

8. Дәүләт органнары булып торучы комиссияләр гражданнарны, аларның берләшмәләре һәм бүтән оешмалар вәкилләрен шәхси кабул итүне үткәрә. Телдән мөрәҗәгатькә турыдан-туры шәхси кабул итү барышында телдән җавап бирелә. Шәхси кабул итү барышында шулай ук язма рәвештә мөрәҗәгать бирелергә мөмкин. Әгәр телдән мөрәҗәгатьтә бәян ителгән шартлар тикшерүне таләп итсә, мондый мөрәҗәгатькә Федераль законда тиешле мөрәҗәгатьне карау өчен билгеләнгән срокта язмача җавап бирелә.

9. Әлеге статья нигезләмәләренең гамәлдә булуы карауның бүтән тәртибе «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда билгеләнгән комиссиягә мөрәҗәгатьләргә кагылмый.»;

4) 18 статьяда:

а) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Әгәр компетенциясенә комиссия әгъзасын билгеләп кую кергән орган комиссия әгъзасының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы карарны 30 көн эчендә, ә сайлаулар билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырылган) көннән алып сайлауларны оештырган комиссия сайлаулар нәтиҗәләрен билгеләгәнгә кадәр чорда – комиссия әгъзасыннан үз вәкаләтләрен туктатуы турында шушы комиссиягә язма рәвештә гариза кергән көннән соң йә аны вәкаләтләрен башкару мөмкинлегеннән мәхрүм итәрлек башка нигезләр барлыкка килгән көннән соң 10 көн эчендә кабул итмәсә, комиссиянең әлеге әгъзасы вәкаләтләрен туктату турындагы карарны составына шушы әгъза кергән комиссия күрсәтелгән вакыт тәмамланганнан соң өч көн эчендә кабул итә.»;

б) 10 өлештә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Сайлаулар билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырылган) көннән алып сайлауларны оештырган комиссия сайлаулар нәтиҗәләрен билгеләгәнгә кадәр чорда компетенциясенә комиссия әгъзасын билгеләп кую кергән орган әлеге статьяның $6 - 6^2$ һәм 8 өлешләрендә күрсәтелгән сәбәпләр белән киткән комиссия әгъзасы урынына яңасын әлеге Кодексның 11, 12, 14 – 16 статьяларында билгеләнгән таләпләр нигезендә аны китү көненнән соң 10 көннән дә соңга калмыйча билгеләп куярга тиеш.», «бер ай эчендә» сүзләрен «утыз көннән дә» сүзләренә алмаштырырга;

в) 16 өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә әлеге Кодексның 16 статьясындагы $6^{1-1}$ өлешендә күрсәтелгән махсус участок комиссиясе әгъзасына компенсация һәм хезмәт өчен өстәмә түләү (бүләкләү) күләмнәрен һәм тәртибен федераль бюджет акчалары исәбеннән Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгели.»;

5) 20 статьяның 2 өлешендә «Россия Федерациясе сенаторы,» сүзләрен төшереп калдырырга;

6) 66 статьяда:

а) 1 өлештә «сайлауларны оештыручыларны һәм сайлаучыларны өйрәтүгә» сүзләрен «сайлаучыларның хокукый культурасын арттыруга, сайлауларны оештыручыларны һәм сайлау процессында башка катнашучыларны өйрәтүгә» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^{1-1}$ өлеш өстәргә:

«$1^{1-1}$. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә әлеге Кодексның 16 статьясындагы $6^{1-1}$ өлешендә күрсәтелгән махсус участок комиссияләренең вәкаләтләрен тәэмин итүгә бәйле чыгымнар федераль бюджет акчалары исәбеннән Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан башкарыла.»;

в) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләү һәм уздыру өчен, автоматлаштырылган чараларны эксплуатацияләү һәм үстерү, сайлаучыларның хокукый культурасын арттыру, сайлауларны оештыручыларны һәм сайлау процессында башка катнашучыларны өйрәтү, комиссияләр эшчәнлеген тәэмин итү, федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга ярдәм күрсәтү өчен счетлар ачу һәм алып бару, Татарстан Республикасы бюджетыннан, җирле бюджеттан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә, башка комиссияләргә бүлеп бирелгән акчаларны исәпкә алу, хисаплылык һәм аларны күчерү тәртибе, Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Акчалар Россия Федерациясе Үзәк банкының исәп-хисап-касса хезмәтен гамәлгә ашыручы учреждениесендә, ә ул Татарстан Республикасы территориясендә булмаган очракта, «Россия Саклык банкы» гавами акционер җәмгыяте филиалларында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан ачыла торган счетка күчерелә. Округ комиссияләренә һәм территория комиссияләренә акчалар күрсәтелгән комиссияләрнең «Россия Саклык банкы» гавами акционер җәмгыяте филиалларында ачыла торган счетларга күчерелә, аның белән банк счеты шартнамәсендә мондый акчаларның кулланылышын тикшереп тору максатларында күрсәтелгән комиссияләрнең «Россия Саклык банкы» гавами акционер җәмгыяте тарафыннан

югарыда күрсәтелгән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе счеты буенча операцияләр турында белешмәләр бирүгә ризалыгы хакында шарт карала.»;

г) түбәндәге эчтәлекле 4[1] өлеш өстәргә:

«4[1]. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә «Россия Саклык банкы» гавами акционер җәмгыяте филиаллары Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә, күрсәтелгән кредит оешмалары һәм Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе яисә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе арасындагы килешүләргә нигезләнеп, түбәнрәк сайлау комиссияләренә ачылган счетлар буенча операцияләр турында белешмәләр тапшыра.»;

7) 69 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Махсус сайлау счеты шәхсән булмаганда да (дистанцион) ачылырга мөмкин.»;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлаулар уздырганда әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән счетларны ачу, алып бару һәм ябу тәртибе, Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Күрсәтелгән тәртиптә референдум фондының махсус счетын шәхсән булмаганда (дистанцион) ачу, алып бару һәм ябуның үзенчәлекләре билгеләнә. Референдум фонды акчаларын керү һәм аларны тоту турында, шул исәптән һәр операция буенча, исәпкә алу һәм хисаплылык тәртибе һәм рәвешләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

8) 70 статьяның 12 өлешендәге икенче җөмләне төшереп калдырырга;

9) 75 статьяның 9 өлешендә «бер төстә эшләнеп» сүзләрен «, бер төстә эшләнеп, бертөрле шрифт белән» сүзләренә алмаштырырга;

10) 76 статьяда:

а) 12 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Әгәр сайлаучы бозылганы урынына яңа бюллетень бирүне үтенеп кабат мөрәҗәгать итсә, мондый бюллетеньне бирү турында карар участок комиссиясе тарафыннан кабул ителә.»;

б) 17 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Сайлаулар уздырганда электрон тавыш бирү үткәрелергә мөмкин. Электрон тавыш бирү үткәргәндә кәгазьдә әзерләнгән бюллетеньнәрне файдалану мөмкинлеге тәэмин ителгән булырга тиеш. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә электрон тавыш бирү үткәрү турындагы карар Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан яисә аның кушуы буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан кабул ителә. Электрон тавыш бирү, сайлаучыларның тавышларын санау тәртибе, тавыш бирү

йомгакларын билгеләү һәм, электрон тавыш бирү йомгакларын исәпкә алып, сайлаулар нәтиҗәләрен билгеләү Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе яисә аның кушуы буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

11) $76^{2}$ статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $10^{1}$ өлеш өстәргә:

«$10^{1}$. Татарстан Республикасы территориясендә берьюлы дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү һәм электрон тавыш бирү үткәрелгән очракта дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү тәртибендә электрон тавыш бирү нәтиҗәләре дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү нәтиҗәләрендә исәпкә алына дип каралырга мөмкин.»;

б) 13 өлештә дүртенче җөмләне төшереп калдырырга;

12) 79 статьяга түбәндәге эчтәлекле $31^{3}$ өлеш өстәргә:

«$31^{3}$. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә тавышларны техник санау чараларыннан, электрон тавыш бирү комплексларыннан, референдум турында мәгълүмат тапшыруның техник системасыннан файдалану тәртибе, күрсәтелгән мәгълүматны тапшыру, эшкәртү һәм аннан файдалану тәртибе һәм вакытлары, шул исәптән тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмәләрдәге мәгълүматларны техник элемтә каналлары буенча тапшырылганнарны да, федераль закон белән, ә федераль закон белән җайга салынмаган өлешендә — Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан яисә аның кушуы буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.».

13) 91 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $2^{1}$ пункт өстәргә:

«$2^{1}$) Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны әзерләүгә һәм үткәрүгә, Россия Федерациясендә сайлау системасын үстерүгә, автоматлаштыру чараларын кертүгә, эксплуатацияләүгә һәм үстерүгә, сайлаучыларның хокукый культурасын арттыруга, сайлауларны оештыручыларны һәм сайлау процессында башка катнашучыларны өйрәтүгә, кирәкле басма продукцияне чыгаруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруны тәэмин итә;»;

б) түбәндәге эчтәлекле $16^{1}$ пункт өстәргә:

«$16^{1}$) әлеге Кодексның 16 статьясындагы $6^{1-1}$ өлешендә күрсәтелгән махсус участок комиссияләренең вәкаләтләрен тәэмин итүгә федераль бюджеттан бүлеп бирелгән акчаларны тотуны гамәлгә ашыра;»;

14) 93 статьяның 3 пунктында «һәм уздыруга» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясендә сайлау системасын үстерүгә, автоматлаштыру чараларын кертүгә, эксплуатацияләүгә һәм үстерүгә, сайлаучыларның хокукый культурасын арттыруга,

сайлауларны оештыручыларны һәм сайлау процессында башка катнашучыларны өйрәтүгә» сүзләрен өстәргә;

15) 104 статьяда:

а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Өстәмә сайлаулар, әлеге статьяның 4 өлешендә каралган очрактан тыш, Дәүләт Советы депутатларын төп сайлауларны уздыру елына кадәрге елда, шулай ук күрсәтелгән сайлауларны уздыру елында билгеләнми һәм уздырылмый.»;

б) 4 өлештә «ә өстәмә сайлаулар уздыру әлеге статьяның 3 өлеше нигезендә каралмаган булса, әлеге Кодексның 6 статьясындагы 3 өлешендә билгеләнгән вакытларда уздырыла торган яңа төп сайлаулар билгеләнә» сүзләрен «Дәүләт Советы депутатларын төп сайлауларны уздыру елына кадәрге елда, мондый вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату көненнән башлап дүрт айдан соңга калмыйча, өстәмә сайлаулар уздырыла, ә Дәүләт Советы депутатларын өстәмә сайлаулар уздыру елында Дәүләт Советы депутатларын яңа төп сайлаулар билгеләнә, алар әлеге Кодексның 6 статьясындагы 3 өлешендә билгеләнгән срокларда уздырыла.»;

16) $104^{8}$ статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $2^{1}$ пункт өстәргә:

«$2^{1}$) Татарстан Республикасы Рәисен сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга, Россия Федерациясендә сайлау системасын үстерүгә, автоматлаштыру чараларын кертүгә, эксплуатацияләүгә һәм үстерүгә, сайлаучыларның хокукый культурасын арттыруга, сайлауларны оештыручыларны һәм сайлау процессында башка катнашучыларны өйрәтүгә, кирәкле басма продукцияне чыгаруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруны тәэмин итә;»;

б) түбәндәге эчтәлекле $14^{1}$ пункт өстәргә:

«$14^{1}$) әлеге Кодексның 16 статьясындагы $6^{1-1}$ өлешендә күрсәтелгән махсус участок комиссияләренең вәкаләтләрен тәэмин итүгә федераль бюджеттан бүлеп бирелгән акчаларны тотуны гамәлгә ашыра;»;

17) $104^{9}$ статьяның 3 пунктында «һәм уздыруга» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясендә сайлау системасын үстерүгә, автоматлаштыру чараларын кертүгә, эксплуатацияләүгә һәм үстерүгә, сайлаучыларның хокукый культурасын арттыруга, сайлауларны оештыручыларны һәм сайлау процессында башка катнашучыларны өйрәтүгә» сүзләрен өстәргә;

18) 123 статьяда:

а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Өстәмә сайлаулар, әлеге статьяның 4 өлешендә каралган очрактан тыш, муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы депутатларын, муниципаль берәмлекнең сайланулы органы әгъзаларын төп сайлауларны уздыру елына кадәрге елда, шулай ук күрсәтелгән сайлауларны уздыру елында билгеләнми һәм уздырылмый.»;

б) 4 өлештә «ә өстәмә сайлаулар уздыру әлеге статьяның 3 өлеше нигезендә каралмаган булса, яңа төп сайлаулар билгеләнә, алар әлеге Кодексның

6 статьясындагы 3 өлешендә билгеләнгән вакытларда уздырыла» сүзләрен «муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын, муниципаль берәмлекнең сайланулы органы әгъзаларын төп сайлауларны уздыру елына кадәрге елда, мондый вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату көненнән башлап дүрт айдан соңга калмыйча, өстәмә сайлаулар уздырыла, ә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын, муниципаль берәмлекнең сайланулы органы әгъзаларын өстәмә сайлаулар уздыру елында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын, муниципаль берәмлекнең сайланулы органы әгъзаларын яңа төп сайлаулар билгеләнә, алар әлеге Кодексның 6 статьясындагы 3 өлешендә билгеләнгән срокларда уздырыла.».

**4 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 44 статьясындагы 9 һәм 10 пунктлары (әлеге Закон редакциясендә), «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы 9 һәм 11 пунктлары (әлеге Закон редакциясендә), Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 69 статьясындагы 1 һәм 3 өлешләре (әлеге Закон редакциясендә) нигезләмәләре, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 23 маендагы 115-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 5 өлешендә күрсәтелгән очрактан тыш, 2026 елның 1 гыйнварыннан соң билгеләнгән сайлаулар, референдумнар уздыруга бәйле барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. «Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 50 статьясы (әлеге Закон редакциясендә), «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 52 статьясы (әлеге Закон редакциясендә), Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 76 статьясы (әлеге Закон редакциясендә) нигезләмәләре 2026 елның 1 гыйнварыннан соң билгеләнгән сайлаулар, референдумнар уздыруга бәйле барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 23 маендагы 115-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә әзерләнде.

Закон проектының максаты Татарстан Республикасы Сайлау кодексын, «Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы һәм «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнарын күрсәтелгән Федераль законга туры китерүдән гыйбарәт.

Закон проектында электрон тавыш бирү үткәргәндә кәгазьдә әзерләнгән бюллетеньнәрне файдалану мөмкинлеге тәэмин ителү бурычы куела. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы территориясендә электрон тавыш бирү үткәрү турындагы карар Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан яисә аның кушуы буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан кабул ителә. Электрон тавыш бирү, референдумда катнашучыларның тавышларын санау тәртибе һәм референдум участогында тавыш бирү йомгакларын билгеләү һәм, электрон тавыш бирү йомгакларын исәпкә алып, референдум нәтиҗәләрен билгеләү Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе яисә аның кушуы буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

Закон проектында махсус сайлау счетларын дистанцион ачу, алып бару һәм ябу мөмкинлеге беркетелгән. Мәсәлән, күрсәтелгән яңа нигезләмә кандидатлар тарафыннан махсус сайлау счетлары буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдаланганда сарыф ителә торган гомуми вакытларын киметәчәк, шулай ук кредит оешмалары бүлекләренә бару ихтыяҗын бетерәчәк. Хәзерге вакытта махсус сайлау счетын ачу өчен барлык кирәкле документлар кредит оешмасы филиалына кандидат йә финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле кандидат вәкиле тарафыннан турыдан-туры үзе тарафыннан (шәхсән үзенең булуы мәҗбүри) тапшырыла.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлауларны, Татарстан Республикасы референдумын, җирле референдумны уздырганда счетларны ачу, алып бару һәм ябу тәртибе, Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Күрсәтелгән тәртиптә референдум фондының махсус счетын шәхсән булмаганда (дистанцион) ачу, алып бару һәм ябуның үзенчәлекләре билгеләнергә тиеш.

Закон проектында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, депутатларын өстәмә сайлаулар Дәүләт Советы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын төп сайлауларны уздыру елына кадәрге

елда билгеләнми һәм уздырылмый дигән кагыйдәне беркетү тәкъдим ителә (моңа депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатканнан соң күрсәтелгән органның хокуклы составта калган очрак керми). Бу очракта Дәүләт Советы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын төп сайлауларны уздыру елына кадәрге елда, мондый вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату көненнән башлап дүрт айдан соңга калмыйча, өстәмә сайлаулар уздырыла, ә күрсәтелгән органнарны төп сайлаулар уздыру елында, мондый вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату көненнән башлап алты айдан соңга калмыйча, яңа төп сайлаулар билгеләнә.

Закон проектында шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә берьюлы дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү һәм электрон тавыш бирү үткәрелгән очракта дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү тәртибендә электрон тавыш бирү нәтиҗәләре дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү нәтиҗәләрендә исәпкә алыну мөмкинлеге каралган.

Закон проектында гражданнарның, аларның берләшмәләренең, башка оешмаларның һәм аларның вазыйфаи затларының мөрәҗәгатьләрен, шул исәптән Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларын һәм референдумда катнашу хокукын гамәлгә ашыруга һәм аларны яклауга бәйле булмаган мәсьәләләр буенча булган мөрәҗәгатьләрен, йә комиссиягә сайлау кампаниясе, референдум кампаниясе чорыннан башка вакытта кергән мөрәҗәгатьләрне сайлау комиссияләре тарафыннан карау тәртибе билгеләнә.

Закон проектында Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләрнең сайлау комиссияләре тарафыннан гамәлгә ашырылуы максатларында аларга Россия Федерациясе халкы турында белешмәләрне үз эченә алган бердәм федераль мәгълүмат регистрындагы белешмәләрне «Россия Федерациясе халкы турында белешмәләрне үз эченә алган бердәм федераль мәгълүмат регистры турында» Федераль законга ярашлы рәвештә файдалану хокукы бирелә.

Моннан тыш, закон проектында республика сайлаулары һәм референдумнары турында законнарны камилләштерүгә юнәлтелгән башка үзгәрешләр каралган.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

# ИСЕМЛЕГЕ

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы закон актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.